**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**от 25.09.2020** **№ 729**

**«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетына административ комиссияләр салган административ штрафларны түләү бурычларын түләтүгә ышанычсыз дип тану һәм исәптән чыгару турында карарлар кабул итү Тәртибенә үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясенең Бюджет кодексының 47.2 статьясы (2020 елның 8 июненә үзгәрешләр белән) (2020 елның 1 июленнән гамәлдәге редакция) 1998 елның 31 июлендәге 145-ФЗ номерлы РФ Кодексы нигезендә, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Биектау муниципаль районы башкарма комитетының 2020 елның 08 маендагы 390 нчы номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетына Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының административ комиссиясе тарафыннан салынган административ штрафларны түләү бурычларын түләтүгә ышанычсыз дип тану һәм исәптән чыгару турында карарлар кабул итү Тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Әлеге Тәртип салым һәм җыемнар турындагы законнар, производствода бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминләштерү турындагы Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән түләүләргә, Евразия икътисадый берлегенең хокукы һәм таможня җайга салуы турындагы Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән гавами-хокукый берәмлек алдындагы акчалата йөкләмәләргә кагылмый.»;

2) 2.1.пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Билгеләнгән срокта түләнмәгән бюджетка түләүләр (бюджетка түләүләр буенча бурыч), түбәндәге очракта түләтүгә өметсез дип таныла:

а) физик затның – бюджетка түләүләрне түләүченең үлеме яисә аны Россия Федерациясе гражданлык-процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә вафат дип игълан ителү;

б) 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы “Бөлгенлек (банкротлык) турында”гы Федераль закон нигезендә шәхси эшмәкәрне - бюджетка түләүләрне түләүчене банкрот дип тану - бурычлының мөлкәте җитмәү сәбәпле түләнмәгән бюджетка түләүләр буенча бурыч өлешендә.;

в) 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы "Бөлгенлек (банкротлык)

турында" Федераль закон нигезендә шәхси эшмәкәр булмаган гражданны банкрот дип тану, күрсәтелгән Федераль закон нигезендә кредиторлар белән исәп-хисаплар тәмамланганнан соң түләнмәгән бюджетка түләүләр буенча бурыч өлешендә;

г) оешманы - бюджетка түләүләрне түләүчене түләнмәгән бюджетка түләүләр буенча бурыч өлешендә оешма мөлкәте җитмәгәнлектән һәм (яисә) аны әлеге оешманы гамәлгә куючылар (катнашучылар) тарафыннан Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чикләрдә һәм тәртиптә каплау мөмкин булмаганга күрә бетерү;

д) штрафка тарту яки суд тарафыннан карар кабул итү рәвешендә җәза алуга хөкем ителгәннәргә карата амнистия турында яки кичерү турында актлар куллану, аның нигезендә бюджет керемнәре администраторы бюджетка түләүләр буенча бурычларны түләтү мөмкинлеген югалта;

е) «Башкару эшчәнлеге турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 яисә 4 пунктында каралган нигезләмә буенча башкарма документны түләтүчегә кайтару турында суд приставы-башкаручы тарафыннан башкарма производствоны тәмамлау турында һәм башкарма документны түләтүчегә кайтару турында карар чыгару, әгәр бюджетка түләүләр буенча бурыч биш елдан артык узган көннән түбәндәге очракларда:

бурыч күләме банкротлык турындагы эш буенча производство ачу өчен бөлгенлек (банкротлык) турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән бурычка карата таләпләр күләменнән артмый;

суд тарафыннан бюджетка түләүләрне түләүчене банкрот дип тану турында гариза кире кайтарылды яки банкротлык турындагы эш буенча кулланыла торган процедураларны уздыруга суд чыгымнарын каплау өчен җитәрлек акча булмау сәбәпле, банкротлык турындагы эш буенча производство туктатылды;

ж) теркәүче орган карары буенча юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан юридик затны төшереп калдыру һәм башкарма производствоны тәмамлау турында 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы «Башкару эшчәнлеге турында» Федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 яки 4 пунктында каралган нигез буенча башкарма документны түләтүчегә кире кайтаруга бәйле рәвештә суд приставы-башкаручы тарафыннан элек чыгарылган карарның булуы - оешманың мөлкәте җитмәү һәм әлеге оешманы гамәлгә куючылар (катнашучылар) тарафыннан Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда аны түләү мөмкинлеге булмау сәбәпле бюджетка түләүләр буенча бурыч өлешендә. Теркәлүче органның юридик затны юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан төшереп калдыру турындагы карары “Юридик затларны һәм шәхси эшмәкәрләрне дәүләт теркәве турында” 2001 елның 8 августындагы 129-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә дөрес түгел дип таныган очрагында, элек әлеге пунктча нигезендә түләтүгә өметсез дип танылган бюджетка түләүләр буенча бурыч бюджет (бухгалтерлык) исәбендә торгызылырга тиеш.»;

3) 2.2. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Әлеге Тәртипнең 2.1 пунктында каралган очраклар белән беррәттән, түләнмәгән административ штрафлар, әгәр Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында каралган очракларда административ җәза билгеләү турында карар чыгарган судья, орган, вазыйфаи зат тарафыннан административ җәза

билгеләү турындагы карарны үтәүне туктату турында карар чыгарылса, түләтүгә өметсез дип таныла.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/, һәм Интернет челтәрендәге Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча урнаштырып бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф. Шәйдуллин